КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 7 май г.Казань № 423

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль мәгариф оешмалары объектларының (территорияләренең) террорчылыктан сакланышын тәэмин итүгә бәйле хезмәт күрсәтүләрне хосусый каравыл оешмаларыннан сатып алуны гамәлгә ашырганда, әлеге хезмәт күрсәтүләр кыйммәте нормативларын билгеләү тәртибе турындагы методик тәкъдимнамәләрне раслау хакында» 2021 ел, 23 ноябрь, 1112 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль мәгариф оешмалары объектларының (территорияләренең) террорчылыктан сакланышын тәэмин итүгә бәйле хезмәт күрсәтүләрне хосусый каравыл оешмаларыннан сатып алуны гамәлгә ашырганда, әлеге хезмәт күрсәтүләр кыйммәте нормативларын билгеләү тәртибе турындагы методик тәкъдимнамәләргә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль мәгариф оешмалары объектларының (территорияләренең) террорчылыктан сакланышын тәэмин итүгә бәйле хезмәт күрсәтүләрне хосусый каравыл оешмаларыннан сатып алуны гамәлгә ашырганда,

әлеге хезмәт күрсәтүләр кыйммәте нормативларын билгеләү тәртибе турындагы методик тәкъдимнамәләрне раслау хакында» 2021 ел, 23 ноябрь, 1112 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль мәгариф оешмалары объектларының (территорияләренең) террорчылыктан сакланышын тәэмин итүгә бәйле хезмәт күрсәтүләрне хосусый каравыл оешмаларыннан сатып алуны гамәлгә ашырганда, әлеге хезмәт күрсәтүләр кыйммәте нормативларын билгеләү тәртибе турындагы методик тәкъдимнамәләргә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктта:

беренче абзацта татар текстында «саклау объектлары өчен» сүзләреннән соң «Татарстан Республикасы бюджеты һәм җирле бюджетлар акчасы исәбеннән» сүзләрен өстәргә;

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Бюджет кодексының 72 статьясы нигезендә каравыл хезмәтләрен сатып алулар чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы Законында, муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнарының чираттагы финанс елына һәм план чорына җирле бюджетлар турында муниципаль хокукый актларында билгеләнгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә гамәлгә ашырыла.»;

3 пунктта:

унынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Методик тәкъдимнамәләр нигезендә исәпләп чыгарылган Татарстан Республикасы бюджеты һәм җирле бюджетлар акчасы исәбеннән саклау объектларының каравыл хезмәтләренә постның бер эш сәгате кыйммәте нормативы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан расланган саклау объектларының каравыл хезмәтләренә постның бер эш сәгате кыйммәте нормативы Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмаларында һәм Татарстан Республикасы муниципаль мәгариф оешмаларында финанслауның башка чыганаклары булганда арттырылырга мөмкин.».

2. Бу карарның гамәле 2022 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин